**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БОЛЬШЕКАБАНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЛАИШЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул.Южная, дом 1, село. Малые Кабаны
422623, Телефон/факс(84378)4-22-02
E-mail: Bkab.La@tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
ОЛЫ КАБАН ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кәньяк урамы,1 нчы йорт,
Кече Кабан авылы,
422623 Телефон/факс(84378)4-22-02
E-mail: Bkab.La@tatar.ru

**2020 елның «22» сентябре** **13 номер**

# КАРАР

## Кадастр номеры 16: 24: 160303:111 булган җир кишәрлеге чигендә территорияне планлаштыру проекты мәсьәләсе буенча ачык тыңлауларны билгеләү турында)

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 39 статьясы, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының «Олы Кабан авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 20 статьясы нигезендә, территориянең тотрыклы үсешен тәэмин итү, инженерлык транспорт һәм социаль инфраструктураны үстерү, гражданнар һәм аларның берләшмәләре мәнфәгатьләрен исәпкә алуны тәэмин итү максатларында, «АКТИВиСТ «ИК» АҖ гаризасы нигезендә, **карар бирәм**:

1. ТР, Лаеш муниципаль районы, Олы Кабан авыл җирлеге, Олы Кабан авылы адресы буенча урнашкан 16: 24: 160303:111 кадастр номеры булган җир кишәрлеге чигендә территорияне планлаштыру проекты мәсьәләсе буенча гавами тыңлаулар билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Олы Кабан авыл җирлегеннән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләре проектын әзерләү буенча комиссиягә 2020 елның 14 октябрендә 18.00 сәгатьтә ТР, Лаеш муниципаль районы, Олы Кабан авылы, Җиңү урамы, 5 нче йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында ачык тыңлаулар үткәрергә.

3. Ачык тыңлауларга чыгарыла торган мәсьәлә буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләрне язмача түбәндәге адрес буенча җибәрергә: ТР Лаеш районы, Кече Кабан авылы, Көньяк ур., 1 йорт яисә факс буенча (8843 78) 4-22-02, 2020 елның 13 октябренә кадәр.

4. Әлеге карарны «Кама ягы»(«Камская Новь») район газетасында һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Олы Кабан авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

**Олы Кабан авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе** **Р.Ш. Илһамов**